5.8.1. — Общая педагогика, история педагогики и образования
**Ссылка для цитирования:**
Гыйләҗева Л. Г., Хадиева Г. В. Туган (татар) телне укытуда компетентлы якын килү // Современное образова-ние: актуальные вопросы и инновации. 2025. № 1 (24).
URL: http://irortsmi.ru/wp-content/uploads/2025/03/2025_1_gilyazova.pdf

УДК 37.01

**Лилия Гыйльметдин кызы Гыйләҗева[1], Гөлнара Васил кызы Хадиева[2]**
[1]доцент, филология фәннәре кандидаты
[2]өлкән укытучы
Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты, Казан, Рәсәй

## Туган (татар) телне укытуда компетентлы якын килү

***Аннотация.*** Мәгарифтә компетентлы якын килү укучыда билгеле бер компетенцияләр формалаштыру тирәсендә төзелә. Бу — укытуның төп максаты һәм нәтиҗәсе, ул исә белем бирү процессын махсус оештыруда да, укытуның эчтәлеген, формаларын, ысулларын һәм чараларын сайлауда да күренә. Туган телдән белем бирүнең максаты — федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләрен тормышка ашыру белән бергә, лексик темаларга нигезләнеп, укучыларда коммуникатив (аралашу осталыгы), лингвистик, социомәдәни компетенцияләр формалаштыру.

***Теләк сүзләр:*** мәгарифтә компетентлы якын килү, белем бирү эчтәлеге, белем бирү процессын оештыру, белем бирү нәтиҗәләрен бәяләү, традицион һәм компетентлы якын килүне чагыштыру.

**Liliya G. Gilyazova[1], Gul'nara V. Khadieva[2]**
[1]Associate Professor, PhD in Philology
[2]Senior Lecturer
Institute for the Development of Education of the Republic of Tatarstan, Kazan, Russia

## Competence-Based Approach in Teaching Native (Tatar) Language

Яңартылган федераль дәүләт белем бирү стандарты укучы шәхесенең үсешен төп максат итеп куйган системалы-эшчәнлекле якын килеп укытуны алгы планга куя. Бүгенге көн белем бирү системасы традицион рәвештә белем һәм күнекмәләр бирүдән баш тарта, Стандарт формулировкасы укучы ия булырга тиеш булган эшчәнлекнең реаль төрләрен күрсәтә, белем алу нәтиҗәләренә таләпләр шәхескә кагылышлы, метапредмет һәм предмет нәтиҗәләр рәвешендә формалаштырыла. Туган (татар) тел курсы гамәлдәге һәм яңартылган белем бирү стандартларына туры китерелеп, барлык өлкәләрдә дә аралашуны булдыру өчен кирәкле булган эшчәнлек төрләрен тәкъдим итә: көнкүреш, социомәдәни, рәсми һәм эшлекле, шулай ук өйрәнелә торган телнең мәдәниятенә якынаю.

Туган телне өйрәнү барышы компетенцияләргә нигезләнә. Компетенция — латинчадан ирешү, тиешенчә ярашу, нигезләү мәгънәсен аңлата. Туган телдән белем бирүнең максаты — федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләрен тормышка ашыру белән бергә, лексик темаларга нигезләнеп, укучыларда коммуникатив (аралашу осталыгы), лингвистик, социомәдәни компетенцияләр формалаштыру.

«Компетентлы якын килү» һәм «төп компетентлылык» төшенчәсе мәгарифне модерни-

© Гилязова Л. Г., Хадиева Г. В., 2025

зацияләү проблемалары һәм юллары турындагы дискуссияләргә бәйле рәвештә күптән түгел генә таралыш алды. Бу төшенчәләргә мөрәҗәгать итү белем бирүдә кирәкле үзгәрешләрне билгеләргә омтылыш белән, шул исәптән мәктәптә, җәмгыятьтә бара торган үзгәрешләр белән бәйле. Төрле галимнәр бу төшенчәне төрлечә аңлата. Кайбер галимнәр мондый билгеләмә бирә: «Компетентлы якын килү — белем бирү нәтиҗәләренә игътибарны юнәлтә торган алым, өстәвенә, нәтиҗәдә үзләштерелгән мәгълүмат суммасы түгел, ә кешенең төрле проблемалы хәлләрдә эш итү сәләте карала».

Компетентлы якын килү дигәндә укучыларның аның җәмгыятьтә уңышлы яраклаша алуын билгели торган төп сыйфатлар булдыру һәм үстерүне күздә тотыла. О.Е. Лебедев фикеренчә, «компетентлы якын килү — ул белем бирү максатларын билгеләүнең, белем бирү эчтәлеген сайлауның, белем бирү процессын оештыруның һәм белем бирү нәтиҗәләрен бәяләүнең гомуми принциплары җыелмасы». Мондый принциплар исәбенә ул түбәндәгеләрне кертә: белем бирүнең мәгънәсе, белем бирүнең эчтәлеге, белем бирү процессын оештыруның мәгънәсе, белем бирү нәтиҗәләрен бәяләү.

Белем бирүнең мәгънәсе «белем бирү сәләтен үстерүдә укучыларның үз тәҗрибәсе булган социаль тәҗрибәне куллану нигезендә төрле өлкәләрдә һәм эшчәнлек төрләрендә проблемаларны мөстәкыйль рәвештә хәл итү сәләтен үстерүдән гыйбарәт».

Белем бирү эчтәлеге «танып белү, дөньяви, әхлак, сәяси һәм башка проблемаларны хәл итүнең дидактик җайлаштырылган социаль тәҗрибәсе»ннән гыйбарәт.

Традицион һәм компетентлы якын килүне чагыштыру

| | **Традицион** | **Компетентлы якын килү** |
|---|---|---|
| Укыту максатлары | Мәктәпне үстерүнең экстенсив юлын саклауга юнәлеш тоту (укучы никадәр күбрәк белем алган булса, шулкадәр яхшырак, аның белемлелек дәрәҗәсе шулкадәр югарырак).<br>Белем бирү максатлары «Мәктәптә укучы нинди яңа белем үзләштерә?» дигән сорауга җавап биреп сурәтләп була торган нәтиҗәне модельләштерә. | Булган белемнәр нигезендә төрле катлаулылыктагы проблемаларны хәл итү сәләтен үстерү (белемнәрнең әһәмиятен кире какмый, алынган белемнәрне файдалану сәләтенә игътибарны юнәлтә.)<br>Белем бирү максатлары «Мәктәп елларында укучы нәрсәгә өйрәнде?» дигән сорауга җавапны күзаллый. |
| Кыйммәтле ориентацияләр формалаштыру юллары | Шәхси нәтиҗәгә кирәкле белем алу исәбенә ирешергә мөмкин | Максат-проблемаларны мөстәкыйль хәл итү тәҗрибәсе алу |
| Көтелгән нәтиҗә | Белемнәрне, төшенчәләрне үзләштерү, типик бурычларны хәл итү сәләте, алгоритм буенча эш итә белү һ.б. | Проблеманы күрә белү, мәгълүматны һәм көтелгән нәтиҗәне анализлау, проблеманы хәл итү өчен кирәкле модель төзи белү, аны анализлау — укытуның мөһим нәтиҗәсе |
| Бәяләү критериясе | Биш баллы бәя шкаласы. Бер үк билгене төрле хаталар ясап алырга мөмкин. | Бәяләү шкаласы киңәя, бәяләү, куелган билгене аңлату, комментарийлар, тәкъдимнәр белән бергә бара. Эшләрне анализлауга зур игътибар бирелә. |
| Белем бирү программасы | Фәннәр (предметлар) буенча программалар бер-берсенә бәйсез рәвештә эшләнә. Алар арасындагы бәйләнешләр иң яхшы очракта гомуми төшенчәләрне аерып чыгару дәрәҗәсендә күрсәтелгән. | Аерым предметлар буенча программа мәктәпнең белем бирү программасы элементы буларак каралырга тиеш. Әлеге программаларны эшләгәндә, аларны мәктәп белеменең билгеле бер этабы — мәктәп баскычы, сыйныф белән бәйләргә кирәк. |

Белем бирү процессын оештыруның мәгънәсе «белем бирү тәҗрибәсендә белем бирү эчтәлеген тәшкил иткән танып белү, коммуникатив, оештыру, әхлакый һәм башка проблемаларны мөстәкыйль хәл итү өчен шартлар тудырудан» тора. Белем бирү нәтиҗәләрен бәяләү «белем бирүнең билгеле бер этабында укучылар ирешкән дәрәҗәләрен анализлауга» нигезләнә. Компетентлы якын килүнең күп кенә идеяләре бүгенге көндә хезмәт базарындагы вәзгыятьне өйрәнү нәтиҗәсендә һәм хезмәткәргә карата куела торган таләпләрне билгеләү нәтиҗәсендә барлыкка килде. Шуңа күрә мәктәп үз укучыларын үзгәрешләргә әзерләргә тиеш, аларда «мобильлек, динамиклык, конструктивлык, инициативалылык, мөстәкыйль карар кабул итә белү» кебек сыйфатларны үстерә.

Укыту максатлары, кыйммәтләргә юнәлеш бирү юллары, көтелгән нәтиҗә, бәяләү критерийлары һәм белем бирү программалары принциплары буенча традицион һәм компетентлы алымнарны чагыштырып карыйк.

Таблицаны караганнан соң, белем бирүдә компетентлы якын килү бүгенге көндә мәгариф өлкәсендә укыту системасына куелган таләпләргә һәм белем бирү процессында катнашучылар мәнфәгатьләренә туры килә, дигән нәтиҗә ясарга мөмкин.

Компетентлы белем бирүнең төп спецификасы кемдер тарафыннан тәкъдим ителгән «әзер белем» түгел, ә белемне укучы үзе этаплап эзли, кабул итүгә нигезләнә. Даими рәвештә тикшерену характерына ия булып, әлеге юл уку эшчәнлеген танып белү, үзләштерү предметы булып куя. Икенче төрле әйткәндә, компетентлы якын килү ул билгеле бер «катып калган» белемнәргә түгел, ә «укырга өйрәтергә» кирәклекне аңлата.

Шулай итеп, татар теле өйрәтүдә компетентлы якын килүнең төп максаты — төрле яклы үсеш алган укучы шәхесен формалаштыру, аның теоретик фикер йөртүен, тел интуициясен һәм мөмкинлекләрен, аралашу һәм үз-үзен тоту культурасын үстерү.

Файдаланылган әдәбият

1. Лебедев, О.Е. Компетентностный подход в образовании / О.Е. Лебедев // Школьные технологии. — 2004. — № 5. — С. 3-1
2. Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында дәүләт теле буларак татар теленә өйрәтү буенча методик тәкъдимнәр. — Казан: ТР МҮИ, 2021. — 64 б.
3. Формирование универсальных учебных действий в урочной работе: разработка и применение компетентностно-ориентированных заданий: Программа модуля повышения квалификации. — Самара: ООО «Арбат», 2013. — 188 с.

References

1. Lebedev OE. Competence approach in education. *School technologies.* 2004;(5):3–1. (In Russ.).
2. Shamsutdinova RR. *Tatarstan Respublikasy gomumi belem biry oeshmalarynda dəylət tele bularak tatar telenə əirəty buencha metodik tək»dimnər=Methodological recommendations on teaching Tatar as a state language in educational institutions of the Republic of Tatarstan* Kazan: IRORT; 2021. 64 p. (In Tatar).
3. *The program of the advanced training module Formirovanie universal'nykh uchebnykh deistvii v urochnoi rabote: razrabotka i primenenie kompetentnost'no-orientirovannykh zadanii: programma modulya povysheniya kvalifikatsii=The formation of universal educational actions in routine work: the development and application of competence-oriented tasks:* Samara: ArbaT; 2013. 188 p. (In Russ.).